Язучы Фоат Садриевның иҗади мирасын өйрәнү, пропогандалау максатыннан

мәктәп укучылары һәм укытучылар арасында
I Төбәкара "Фоат Садриев укулары – 2014"
нигезләмәсе

1. Фоат Садриев укулары Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, якташ язучыбыз иҗатын өйрәнү, пропагандалау, 2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру һәм укучыларда тикшерү, коммуникатив хәбәрдарлык формалаштыру, фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү максатыннан үтәрелә.

2. Катнашучылар:

Төбәкара Фоат Садриев укулары гомуми белем бирү оешмаларының, гимназия, лицейларның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, 8-11 нче сыйныф укучылары катнаша.

3. Бәйгене оештыручылар

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге, Татарстан Республикасы язучылар Союзы, Мөслим муниципаль районының мәгариф бүлеге.

4. **Үткәрү шартлары һәм тәртибе**

Бәйге 2 турда үткәрелә:

4.1. I тур - 2014 нче елның 15 нче мартына кадәр оештыру комитеты бәйгедә катнашу өчен гаризалар, фәнни эшләр, тезислар кабул итә. Гариза, тезис һәм фәнни эшне nurania.shai@edu.tatar.ru адресына җибәрергә кирәк (Хәбәрләшү өчен тел.: 8(85556) 2-40-49, 89274804700 - Нурания Әзһәмовна; 8(8342)33-75-98, 89093088105 – Сиринә Миннегалимовна).

4.2. 17 нче марттан 21 нче мартка кадәр эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм иң яхшы эшләргә чакыру җибәрелә.

II тур - 28 нче март көнне Мөслим гимназиясендә үткәрелә. (Адрес: Мөслим авылы, Кооператив урамы, 170 нче йорт).

Укытучы яки укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, мастер-класс, проект эше)

Эзләнү эшләренә түбәндәге юнәлешләр тәкъдим ителә:

"Фоат Садриев иҗаты: заман һәм шәхес" (укучыларның фәнни-эзләнү эшләре өчен)

- Ф.Садриев әсәрләрендә шәхес язмышы һәм бүгенге җәмгыять;
- Ф.Садриев драмаларында характерлар һәм конфликт;
- Ф.Садриев әсәрләрендә табигать һәм шәхес бергәлеге;
- Ф.Садриев әсәрләрендә милли мәсьәлә һәм халык язмышы;
- Ф.Садриев әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре;
- Ф.Садриев әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше;
- Ф.Садриев әсәрләрендә Ана образы;
- Ф.Садриев әсәрләрендә Ата һәм Ул мөнәсәбәтләре;
- Ф.Садриев әсәрләрендә татар гаиләсе әхлагы мәсьәләсе;
- Ф.Садриевның драма театрлары белән хезмәттәшлеге;
- Ф.Садриев – хикәяләү остасы;
- Ф.Садриев – пейзаж тасвирлау остасы;
- Ф.Садриев – драматург;
- Ф.Садриев – прозаик;